СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

# КАРАР

от «19» октября 2017г. № 1

**Төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Наласа авыл җирлеге Уставы, Наласа авыл җирлегендә, Наласа авыл җирлеге Советының 2009 елның 19 октябрендәге 44 номерлы карары белән (2012 елның 13 февралендәге 27 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Наласа авыл җирлегендә халык хокукларын муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу өчен гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1.Наласа авыл җирлеге Советының карары белән расланган Наласа авыл җирлегенең Җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларын 07.11.2017 елга билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны Наласа авыл җирлеге Советының «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча 10.00 сәгатьтә ТР, Арча муниципаль районы, Наласа авылы, М.Вахитов урамы, 64 йорт адресы буенча үткәрергә.

3. Наласа авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә тәкъдим ителә торган үзгәрешләр буенча гражданнарның тәкъдимнәре, искәрмәләре һәм гавами тыңлауларда катнашуга гаризалары язмача рәвештә 16 сәгатькә кадәр җибәрелә дип билгеләргә. 07.11.2017 елга кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрергә: ТР, Арча муниципаль районы, Наласа авылы, М.Вахитов ур., 64 йорт, тел.(84366)50225.

4. Әлеге карарны һәм Наласа авыл җирлеге Советының «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карары проектын Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова